РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 39

27 сентябрь, 2018 ел

**2014 елның 18 декабрендәге 36нчы номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча, Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турындагы Килешүне раслау турында» Түбән Кама шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе 4 кисәге нигезендә, Түбән Кама шәһәре Уставына таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2014 елның 18 декабрендәге Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турындагы Килешүгә үзгәрешләр кертү Килешүен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Түбән Кама муниципаль районы Советына карарның 1 пунктында күрсәтелгән Килешүне расларга тәкъдим итәргә
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеше буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

**2014 елның 18 декабрендәге Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турындагы Килешүгә үзгәрешләр кертү турында**
**Килешү**

Түбән Кама шәһәре 27 сентябрь, 2018 ел

Шәһәр Уставы нигезендә эш итүче Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Баландин Денис Иванович, бер яктан, һәм район Уставы нигезендә эш итүче Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Сәйфетдинов Айдар Габдуллаҗан улы, икенче яктан, бергә "Яклар" дип аталучылар, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

**Килешү предметы**

Әлеге килешү нигезендә, Яклар 2014 елның 18 декабрендәге Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча, Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турындагы Килешүне түбәндәге вәкаләтләр белән тулыландырырга карар кылдылар:

« - муниципаль учреждениеләр һәм җирлек предприятиеләренә карата эчке финанс контролен гамәлгә ашыру»

**Йомгаклау нигезләмәләре**

Әлеге Килешү 2 (ике) нөсхәдә төзелгән, бертигез юридик көчкә ия һәр Якка берешәр нөсхә.

| | |
|---|---|
| Түбән Кама муниципаль районы<br>Башкарма комитеты<br>Адрес: 423570,<br>Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 12<br>Татарстан Республикасы<br>Түбән Кама муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе | Түбән Кама шәһәре<br>Башкарма комитеты<br>Адрес: 423570,<br>Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 12<br>Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе |
| _______________ А.Г.Сәйфетдинов | ______________________ Д.И.Баландин |